“ Әдәп төбе – матур гадәт” проекты буенча

Совет районы 253 нче балалар
бакчасы тәрбиячеләре
Шафигуллина Ф.М
Закирова Р.С

# Гаилә- тормыш учагы

( Ата-аналар катнашында өлкәннәр төркеме өчен шөгыль)

*Максат.*Балаларның туганнарына , интәшләренә карата җылы, ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү, гаиләнең татулыгы нәрсәгә бәйле икәнен аңлату: бер-береңә игьтибарлы булу, ярдәмләшү, туганлык хисләре, җылы караш тәрбияләү. Балаларның сөйләм телләрен үстерү, өлкәннәрне игътибар итәргә, сүз тыңлаучан булырга өйрәтү.Балаларда гаилә әгъзалары, туганнары, аларның тормышларына карата кызыксыну уяту.
*Ярдәмлек.*ай, йолдызлар, уен өчен шәлләр, бияләй, носки, башлык, кофта: рәсем - өчен кәгазьләр, буяулар, пумалалар, трафаретлар, магнитофон язмасы.

*Эшчәнлек барышы*

(Балалар керәләр һәм исәнләшәләр)

*А.Б* Исәнмесез хөрмәтле кунаклар
Менә сез дә килеп җиткәнсез.
Безнең бакчабызның тормышын
Күреп китик әле дигәнсез.

*А.Б* Исәнмесез хөрмәтле кунаклар
Хәерле көн сезгә бу җирдә
Бакчабыз яраткан бу җыенга
Чакырабыз хәзер сезне дә.

Балалар, әйдәгез кичәбезне башлыйбыз. Күрәсезме, бездә бүген кунакта безнең әбиләребез һәм безнең әниләребез.
Әйтегез , әле балалар нәрсә ул гаилә?.
Балалар : гаилә ул -әти, әни, әби, бабай, энем, сеңелем һ.б.
Уен: “ Кем кемгә ничек туган?”
Балалар бер-берсенә сораулар бирәләр:
- син әтиеңнең кеме буласың?

- Син әниеңнең кеме булаың?
- Син бабаңның кеме буласың?
- Син әбиеңнең кеме буласың?
- Әниеңә син кем буласың?
- Әтиеңә син кем буласың7

*А.Б* Бармакларны уйнатыйк
Кем яши сезнең гаиләдә
Тиз генә шуны әйтик.

Бармак уены уйнала.

Бу бармагым - әнием
Бу бармагым - әтием
Бу бармагым - бабаем
Бу бармагым - әбием
Бу бармагым мин үзем

*А.Б.* Бу бармагым әнием дидегез. Аның куллары турында шигырь сөйләп китик әле.

*Бала.* Синең куллар , әнкәй ( Ә.Атнабаев шигыре)

Ана безне тудырган,
Ана безне үстергән
Ана сөте гомерлеккә
Җитә торган көч биргән.

Авырсаң, янда тора ул,
Төн буе керфек какмый,
Үз саулыгын да кызганмый,
Ул безне саклый, саклый.

Йөзең синең һәрвакытта
Балкып тора , әнием,
Аш-суыңнан тәмле исләр,
Аңкып тора, әнием.

Нинди назлы , нинди эшчән
Синең куллар, әнием!
Бөтен дөнья бәйрәм итә
Сине зурлап , әнием.

*А.Б.*Бу нәфис куллар һәм бармаклар миндә дә, әбиемдә дә, әниемдә дә һ.б бар Олы кешеләрнең нәфис бармаклары бәйләгән җылы киемнәр салкын көннәрдә балаларны җылыта, салкыннан саклый.

(Балалар мода күрсәтәләр: аларда бияләй, башлык, кофта, йомшак ак шәл)

*А.Б.*Күрәсезме, нинди матур шәлләр, аларны битләрегезгә якынрак китерегез. Тоясызмы, нинди йомшак, җылы алар. Ә хәзер иңнәрегезгә салыгыз.

*Балалар.*Алар җылы, матур, ап-ак һәм җиңел.

( Татар халык көе яңгырый. “Шәл салыш “ уены ата-аналар һәм балалар катнашында уйнала.)

Шәлләр салыш кызык уен
Ул сизгерлекне сорый.
Дуслар ярышкан вакытта
Кул чабып тормый булмый.

*А.Б.* Балалар , уйлап карагыз әле, өлкәннәрне үзләрен ничек җылыта, назлый алабыз соң. Әйе, тәмле сүзләр өйтеп шәлгә төрәбез.

(Уен “ Тәмле сүзләр”.Балалар бер җылы сүзләр әйтеп әниләрен, әбиләрен шәлгә төрәләр).

*А.Б.* Балалар , без сезнең белән хыялланырга яратабыз. Менә шушы шәлләргә төренеп хыял дөнъясына чумабыз. Күзләрегезне йомыгыз әле. Төнге күк йөзен күз алдына китерегез.

( Ут сүнә- бер йолдыз яна)

*А.Б.* Күк йөзе караңгы, күктә бары тик бер кечкенә генә йолдыз яна. Көннәрдән бер көнне бу йолдыз тирә-якка күз салса, үзенең ялгыз икәнен аңлый һәм ялгызлык аны бик куркыта башлый. Ул үзенең дуслары, туганнары булуын тели, алар белән уйныйсы, аларның якты нурларында коенасы, назланасы килә. Ялгыз йолдыз шушы теләкләр белән тирә- якка күз салса биек-биек таулар күрә. Бу тауларда бер тылсымчы яши һәм йолдыз бу тылсымчыга мөрәҗәгать итә. Ялгыз булганда җырлыйсы да, уйныйсы да килмәгәнен, ашаган ашларның тәмле булмаганын белә ул тылсымчы, йолдызга бик теләп ярдәм итә. Тылсымчы таягын ала да нәрсәдер әйтә һәм күк йөзендә бик күп төрлетөрле йолдызлар кабына.

( Төрле- төрле утлар кабына. )

*А.Б.*Йолдызлар бер-берсен күргәч шундый шатланалар һәм түгәрәктә әйләнә башлыйлар. Әйдәгез, балалар бездә аларның шатлыкларын уртаклашабыз. Сезнең дә һәм ата-аналарның да йолдызлары бар, карагыз әле нинди төстә , нинди зурлыкта алар, пар йолдызларны табып парлашып әйләнәбез.

(Ата-аналар һәм балалар белән берлектә “ Парлашу” уены)

Сандугачлар , былбыллаар
Тургайлар парлы була.
Кем уенда парсыз кала,
Шундук җәзасын ала.

( Парсыз калган ата-аналарга һәм балаларга җәза бирелә)

*А.Б* Әйе, балалар йолдызлар һаманда әйләнә-әйләнә үзләренең нурларын җир өстенә сибәләр һшм бөтен тирә-якны яктырталар. Тылсымчы аска караса, өлкәннәрнең дә, балаларның да күктәге йолдызларга сокланып карап торуларын күрә.Ул Һәрбер баланың үз йолдызы булсын, мәңге сүнмәсен, балалар бәхетле булсыннар дигән теләктә кала.

Әйдәгез, балалар үз йолдызларыбызны кабызабыз.

( Триз буенча “ Йолдызлар “ рәсемен ясау)

*А.Б.*Күрәсезме ,балалар нинди якты, матур яналар безнең йолдызларыбыз.

Бала һәм әни шигырь сөйлиләр

Әниемә

*Бала* Кайчагында минем бик тә
Йолдыз буласым килә.
Күктә йолдызлар янына
Менеп кунасым килә.
Хикмәтен әгәр белсәм,
Әкияттәге шикелле
Йолдызга әверелсәм.
Әнием төннәр буенча
Һаваны күзләр иде,
Күпме йолдыз арасыннан
Гел минеэзләр иде.
Кайтып кергәч әни башта
Аптырап калыр иде,
Таныгачтын мине шундук
Кочаклап алыр иде.

*Әни* Куанычларым, шатлыгым булып
Балам багалмам, үсәрсеңме син.
Сагынып җырлар җырыма минем
Күземнең нуры, күчәрсеңме син.
Әнием диеп, кадерлем диеп
Сандугачкаем, дәшәрсеңме син?

( балаларның уч төбенә йолдызчыклар салына)

*А.Б.*Балалар, сезнең учыгызда йолдызчыклар, сизәсезме, бөтен тәнегез буенча җылылык һәм наз тарала.Бу назны, җылылыкны туганнарыбыз, дусларыбыз, һәм барча кешеләр белән бүлешәбез. Шундый кешенең генә йолдызы сүнми, мәңге яна.( балалар уч төбендәге йолдызчыкларны ата-аналарга өреп җибәрәләр).

*Балалар.*Яраткан кешем булсын сиңа минем йолдызым.

Ата-аналар һәм белән күмәк “ Татар халык биюе”.

*А.Б* Нинди олы бәхет ! Җыелышып
Уйнау- көлү, бию гел бергә
Насыйп булсын иде сөенешеп
Шатланышып яшәү гомергә.
Дуслык җебе өзелмәс ул
Моңлы халык бар җирдә
Безнең шушы очрашу
Истә калыр гомергә.

“ Балаларга фатыйха” җыры яңгырый. Балалара хушлашалар һәм төркемгә чыгалар.